
ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!

ОКТЯБРЬ,
2015 нче ел

№2 (20)






## Сез - иң гүзәл кеше икәнсез

Көзнең күркәм, ямьле бәйрәмнәренең берсе – Укытучылар көне. Кешене тәүге тапкыр хәреф танытудан башлап, олы тормыш юлына беренче адымнарын атлаганчыга кадәр тәрбияләгән, аңа белем биргән укытучының хезмәте - бәһасез. Зур хөрмәткә лаек, авыр да, катлаулы да хезмәт ул укытучы эше. Укучыларның ышанычын аклау, укытучы дигән изге сүзгә тап төшермичә хезмәт иту җиңел түгел. Бары тик балаларны яратып, үзенең бөтен гомерен белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган кешеләр генә чын укытучы - остаз булырга лаек.

Кадерле укытучылар! Сезне чын күңелдән һөнәри бәйрәмегез белән тәбрик итәбез. Йөзегездә бервакытта да елмаю сүнмәсен, укучыларыгыз сәләтле һәм тырыш булсын! Якыннарыгызның ихтирамын тоеп, шатланып-куанып яшәсәгез иде!

### Бу санда:



| | |
|---|---|
| Картлыкның да үз яме бар! | 2 |
| Якыннан танышыйк! | 3 |
| Көзге бал гөрләп узды | 4 |
| Юбилееңбелән, мәктәбем! | 4 |
| Һөнәрем—язмышым | 4 |
| Мәктәбебезнең бүгенгесе һәм киләчәге | 5 |
| Котлыйбыз! | 6 |

# Картлыкның да үз яме бар…




Без өлкән апа-абыйларны **1 октябрьдә** билгеләп үтелүче Халыкара өлкәннәр көне белән ихлас күңелдән котлыйбыз.

Илебез өчен иң авыр һәм катлаулы чорда көчегезне, сәламәтлегегезне кызганмыйча, вакыт белән исәпләшмичә эшләгәнсез. Ватаныбызның куәтен арттыру өчен, үзегезне аямыйча, киләчәк буыннарның бәхетле тормышта яшәве турында кайгырткансыз. Сезнең барчагызның тормыш юлы сок-ландыргыч һәм




һәркемнең күңелендә чиксез хөрмәт хисләре уята.

Хөрмәтле ветераннар! Шушы олы бәйрәмне барыгызның сау – сәламәт каршылавыгызны, исән-имин булуыгызны, бәхетле яшәвегезне телибез.

Киң күңелегез, юмартлыгыгыз

# Иркен минем туган илем

**23 нче октябрь көнне мәктәптә география укытучыларының район семинары үтте.**



Семинарда укытучылар 5 нче сыйныфта "Галәмне өйрәнү: Коперниктан башлап бүгенге көнгәчә" темасына дәрес, 7-9 сыйныф укучылары катнашында "Иркен минем туган илем" дип аталган әдәби – географик чара карадылар.



Дәресне география укытучысы Л.Ю. Хәйруллина, чараны татар теле һәм әдәбияты укытучысы Г.Д.Аглиуллина һәм рус теле һәм әдәбияты укытучысы К.К.Ситдикова үткәрделәр.

## “Хуш исле” үлән гүргә кертә

Сентябрьдә генә дә Россия регионнарында синтетик тарту катнашмалары – спайслар кулланып 700дән күбрәк кеше агуланган, шуларның 25е үлгән. Корбаннар арасында мәктәп укучылары да бар. 1 нче каналдан трансляцияләнүче “Әйдә, сөйләсеннәр” тапшыруының бер чыгарылышы әлеге вакыйганы анализлауга багышланды. Ә хәзер наркотиклар белән хәл ничек? Спайс - төрле химик матдәләр белән эшкәртелгән үләннәр рәвешендә сатыла. Гаять куркыныч наркотик. Спайс кешенең аңын “җимерә” – анда нигезсез курку, паника, галлюцинацияләр барлыкка килә, мондый наркотик кулланучылар арасында үз -үзенә кул салу очраклары да күп. Спайсларның организмга хәтәр тәэсире турында сөйли-сөйли арыдык. “Кәефләндергеч”кә күбесенчә 20-25 яшьлекләр үрелә. Исәптә торучылар барысы да диярлек спайска “утырганнар”. Хәзер героин, марихуана һәм башка наркотиклар заманы артта калды.

Ни өчен спайслар? Синтетик наркотиклар нәрсәсе белән шулкадәр җәлеп итә соң? Беренчедән, бәясе түбән булуы белән. Икенчедән, аларны ирекле сатып алу мөмкинлеге бар. Дөрес, күпчелеген куллану Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә законлы тыела. Ләкин тыючы исемлекне һаман тулыландырып торырга туры килә, чөнки синтетик наркотиклар әледән-әле яңарып тора. Наркотик таратучыларга җәза да катгый инде, югыйсә...

Иртәме-соңмы наркотик белән бәйле җинаять кылучылар барыбер “эләгәләр”.

Наркотик кулланучыларның ата-аналары, якыннары “ак үлем” таратучыларга карата закон йомшак, хокук саклау органнары эшләми, диярргә яраталар. Мин бу фикер белән килешмим. Контроль гаиләдән башлансын иде. Наркотиклар хәзер “контактсыз” юл белән, икенче төрле әйткәндә, интернет аша да таратыла. Шуңа да өлкәннәр балаларының, якыннарының интернет, телефон аша кем белән язышуына, аралашу даирәсенә игътибар итсеннәр иде.

# Якыннан танышыйк!





**Укучыларның сорауларына мәктәпнең биология-химия укытучысы Мәхмүтова Рәмзия Рәхимовна җавап бирә.**

-- Балачакта Сез кем булырга теләгән идегез?

- Мин табиб булырга хыялланган идем, тик әти—әнием рөхсәт итмәде..

- Мәктәптә укыган вакытта Сезнең яраткан фәннәрегез?

- Мин бигрәк тә физик тәрбия һәм биолгия дәресләрен зур түземсезлек белән көтеп ала идем.

- Яраткан укытучыгыз дип кемне саныйсыз?

- Яраткан укытучыларым Исмаил абый һәм Илдус абый иделәр.

Начар билге алганыгыз булдымы?

- Гомумән, начар билге алганымны хәтерләмим.

-Нишләп укытучы һөнәрен сайларга булдыгыз?

- Укытучы һөнәрен сайларга балаларны нык яратуым этәргеч булды.

- Сезнең хоббиегыз нинди?

- Мин чәчәкләр һәм волейбол уйнарга яратам. Шуңа күрә бакчам төрле чәчәкләргә күмелеп утыра. Ә өемдә тәрәз төбендә үсеп утыручы гөлләрем җаныма рәхәтлек бирә.

**Әңгәмәне Рәзилә Абдрахманова алып барды**



## Көлке хикмәте

********

Кешенең нерв системасы өчен иң зыянлы нәрсә -



әкрен эшләүче интернет.

********

Аптекага даруга кердем, бәяләрне күргәч: «Үлүең очсызракка төшә", -дип уйладым. Юл уңаеннан "Ритуаль хезмәт"ләргә сугылдым, бәяләрне күргәч, кабат аптекага әйләнеп кайттым.

*******

# КӨЗГЕ БАЛ гөрләп узды




Алтын көзнең икенче ае да үтеп бара. Көз минем күңелемә искиткеч матур, чуар төсләре белән якын. Мин төрле төстәге яфракларның коелуын күзәтергә яратам. Көздән дә матуррак ел фасылы юктыр. Ул рәссам кебек, төсләр белән уйнарга оста.

Мәктәбебездә гөрләп үткән Көзге балда да без шуны расладык.

Бу бәйрәмне оештыру 4, 6 һәм 9 сыйныфларга йөкләнгән иде. Шулкадәр мавыктыргыч биремнәрне үткәрү күңелдә рәхәтлек һәм канәгатьләнү хисләре тудырды. Ярышлар бик күңелле узды һәм барыбызга да ошады.

***Гайшә Таһирова***

## Ни чәчсәң, шуны урырсың

Мәктәп янындагы участокта без кишер, суган, чөгендер, помидор, борыч, кыяр, кәбестә үстердек. Тырыш хезмәтнең нәтиҗәсе дә бар. 4712 кг кишер, 2,5 т суган, 1626 кг чөгендер саттык, ә үзебез ел әйләнәсендә ашханәдә түләүсез ашыйбыз.

***Аяз Әхлиуллин***



# *ЮБИЛЕЕҢ БЕЛӘН, МӘКТӘБЕМ!*



## Бәйрәмнән фоторепортаж








**3 октябрь көнне кунакларны кабул итүче мәктәп коллективыннан бигрәк, килүчеләр күбрәк дулкынлангандыр. Элекке елларда монда укучылар, белем биргән ветеран-укытучылар үзләре дә парта артына утырып, балачакларына әйләнеп кайтты!**

Тантана кунакларның хатирәләре һәм мәктәп укучыларының чыгышы белән үрелеп барды. Район башлыгы Равил Кузюров мәктәп коллективын, ветераннарны, укучыларны юбилейлары белән кайнар котлады.

Юбилей алдыннан мәктәп укытучылары уку йортының тарихын да барлаган икән – үзләре төшергән видеоязма, презентацияләрдә 50 еллык тарихны чагылдырганнар. "Үз мәктәбеңә ярдәм ит!" акциясе кысаларында иганәчелек ярдәме күрсәтүчеләрне дә онытмаганнар, директор Халим Салихович һәрберсенә Рәхмәт хаты тапшырды. Бәйрәмнең икенче өлеше матур итеп бизәлгән залда, мул табын өстәлләре артында башланып китте. Бу мәктәптә төрле елларда эшләп киткән хезмәткәрләр Фома урта мәктәбенә ничек килеп урнашу тарихларын, нинди вазыйфа башкаруларын сөйләделәр, мәктәпкә үзләре исеменнән бүләкләр тапшырдылар. Аларның әйтәсе сүзләре, теләкләре күп җыелган иде . Ә чыгарылыш укучылары беренче укытучылары, класс җитәкчеләре, үзләре укыган вакытта уздырылган кызыклы чаралар, вакыйгалар турында сөйләделәр, мәктәп укучыларына киңәшләрен бирделәр. Хәзерге вакытта безнең арада булмаган, фидакар хезмәт күрсәткән укытучыларны да онытмадылар.

Фикер алышулар, хатирәләрне бүлешүләр тантанадан соң да дәвам итте. Күңелләрне кузгатты, Фома мәктәбендә белем алган һәркемнең йөрәгенә барып җитте бу бәйрәм.

Юбилей кичәсен әзерләү һәм үткәрү укытучылар коллективыннан да, укучылардан да бик күп хезмәт таләп итә. Кичәне уздыруга зур көч куйган, мәктәбебезнең алыштыргысыз укытучыларына һәм укучыларына анда эшләүче барлык хезмәткәрләргә бик зур рәхмәт! Эшләрендә уңышлар, сәламәтлек теләп калабыз.

# Һөнәрем - язмышым



**Әхмәтҗанов Лотфирахман Миннегол улы**

Шөгер(хәзерге Лениногорск) районының Кирлегеч авылында туа.

1927-1935 елларда туган авылының җидееллык мәктәбендә, аннары урта мәктәптә укый. 1956 нчы елда Казан дәүләт педагогия институтының тарих – филология факультетын тәмамлый. Фома урта мәктәбендә 1948 елдан 1957 елга кадәр – 50 елга якын укытучы, директор булып эшли. "Халык мәгарифе отличнигы" (1980), күкрәк билгесе, мактау грамоталары белән бүләкләнә.



**Абдуллина Роза Вәлиәхмәт кызы** (1.10.1949), Октябрь (хәзерге Нурлат) районының Киекле авылында туа. Киекле урта мәктәбендә белем ала. 1972 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый. Аннары, 1966 нчы елдан 2011 нче елга кадәр, бер үк мәктәптә – октябрь (хәзерге Нурлат) районының Фома урта мәктәбендә укыта. Авыл Советы рәисе булып та сайлана.

"Халык мәгарифе отличнигы" (1984), "Мәгърифәттәге хезмәтләре өчен" (2004) күкрәк билгеләре, муниципаль район башлыгының гранты, мактау грамоталары белән бүләкләнә.





**Вахитова Клара Солтан кызы** (12.10.1932, Буа шәһәре) – педагог.

Буа башлангыч мәктәбендә, аннары Апас районының Дәвем җидееллык мәктәбендә укый. 1951 елда Казан педагогия училищесын тәмамлап 1960 елда Мәләкәс (хәзерге Димитровград шәһәре) дәүләт педагогия институтының филолгия факультетын тәмамлый. 1951-1952 елларда Октябрь (хәзерге Нурлат районы) Биккол авылында укыта. 1952 елдан 1999 елга кадәр - Фома урта мәктәбе укытучысы. ТАССР мәктәпләренең атказанган укытучысы (1971). Хезмәт ветераны.



**Хафизова Нәгыймә Нурлыгаян кызы.**

Педагог Актаныш районының Иске Әгъбәз авылында туа (22.12.1944).

1963 нче елда Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый һәм шуннан соң 2002 нче елга кадәр) Октябрь (хәзерге Нурлат) районының Фома урта мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. Укытучы – методист. "Халык мәгарифе отличнигы" (1987) күкрәк билгесе, һәм Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгының мактау грамотасы (1998) белән бүләкләнә.



**Кәримов Минсәлим Мирзаҗан улы** (12.01.1937) Октябрь (хәзерге Нурлат) районының Фома авылында туа. Фома җидееллык мәктәбендә укый, аннары 1955 нче елда Мәләкәс (хәзерге Димитровград шәһәре) педагогия училищесын һәм 1960 елда шул ук шәһәрдә педагогия институтын тәмамлый. Аның хезмәт кенәгәсендә бер генә эш урыны теркәлгән: Фома урта мәктәбе. Бирелә 40 ел буена (1960 -2000 еллар) башта уку – укыту бүлеге мөдире, аннары директор булып эшли. Татарстан Республикасының атказанган укытучысы (1994). «РСФСР һәм СССРның халык мәгарифе отличнигы" күкрәк билгеләре; тармакның, республиканың, районның күпсанлы мактау грамоталары белән бүләкләнә.



***Нуруллин Салих Шакирович***

Туган җире — Октябрь (хәзерге Нурлат) районының Зирекле авылы).

Иске Зирекле сигезьеллык һәм Биләр Күле урта мәктәпләрендә укый. Алабуга педагогия институтын тәмамлый. Педагогия эшчәнлегенең башы: Фома урта мәктәбендә рус теле дәресләрен алып бара, укыту—тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып тора. "Россия Федерациясе гомумбелем бирүнең мактаулы хезмәткәре» күкрәк билгесе белән бүләкләнә.

# Мәктәбебезнең бүгенгесе һәм киләчәге



Бүген Фома урта мәктәбен **Сафиуллин Хәлим Салих улы җитәкли.** Хәлим Салихович – 25 ел гомерен авыл балаларына белем бирүгә багышлаган югары категорияле белгеч, гомуми белем бирү өлкәсендә Татарстан Республикасы мәгариф министрлыгының “Мәгарифтәге казанышлары өчен” күкрәк билгесенә һәм “Россия Федерациясе гомумбелем мәктәбенең мактаулы хезмәткәре” исеменә лаек булган талантлы педагог.

Ул үзен оста оештыручы, акыллы җитәкче буларак та танытты. Шушы кыска гына вакыт эчендә Хәлим Салихович үзе җитәкләгән мәктәп коллективын районда гына түгел, республика күләмендә дә танытып өлгерде. Иң мөһиме, балаларга төпле белем һәм лаеклы тәрбия бирүче укытучылар коллективы туплады, алдынгы инновацион мәйданчык буларак, район һәм республикакүләм генә түгел, республикаара семинарлар оештырырлык шартлар да тудырды.

Әйе, бередәге матди-техник база башкала мәктәпләре дә көнләшерлек. Һәр класс бүлмәсе фән кабинеты буларак җиһазландырылган, компьютерлаштырылган. Мәктәптә 3 компьтер классы, 10 интерактив такта, 10 проектор, көнкүреш, ОБЖ кабинетлары, остаханә эшләп килә. Һәр укытучы ноутбук белән эшли. Мәктәптәге һәр компьютер локаль челтәргә тоташкан. Барлык компьютерлар, ноутбуклар исә Wi-Fi аша Интернетка тоташкан.

Максатчан эшнең нәтиҗәсе дә куанычлы. Укучыларның бердәм дәүләт имтихан нәтиҗәләренең елдан-ел күтәрелә баруы, аерым фәннәрдән район һәм республика күрсәткечләреннән югарырак булуы күп нәрсә турында сөйли.

Укучыларыбызның фәнни-тикшеренү юнәлешендәге эшчәнлекләре дә активлашты. Укытучылары белән бергәләп авыл халкының җирле сөйләмен, язучылар иҗатының үзенчәлекләрен, мәктәп тарихын өйрәнәләр, эзләнү эшләре алып баралар. Төрле дәрәҗәдәге фәнни тикшеренү конференцияләрендә катнашучы укучыларның һәм укытучыларның эшләре фәнни җыентыкларда басыла килә.

Фома урта мәктәбен алтын һәм көмеш медальләргә тәмамлаган укучылар да бик күп. Мәктәпнең беренче медалистлары 1990 нчы елгы чыгарылышта була. Болар – Мөхәммәтшина Гөлназ һәм Вәлиуллина Лилия. Тагын да сөенечлесе шул: кызлар педагогик институт тәмамлап туган мәктәпләренә эшкә кайттылар һәм бүген дә яшь буынга тырышып белем һәм тәрбия бирәләр.

Бу җиңүләрнең, уңышларның барысында да Хәлим Салиховичның хезмәте җитәкче буларак та, идея бирүче иҗади шәхес буларак та бәяләп бетергесез. Аның педагогик эшчәнлеге төрле дәрәҗәдәге диплом һәм Рәхмәт хатлары белән бәяләнеп тора.

Коллектив - “Ел мәктәбе-2003” конкурсында лауреат, 2006 елда “Мәгариф” милли проектында Россия Федерациясендә инновацион белем программаларын тормышка ашыручы белем учреждениеләре конкурсы җиңүчесе буларак, Россия Президентының 1 миллион сумлык грант иясе, 2008 елда Татарстан Президентының 1 миллион сумлык грант иясе, 2009 елда “Матур мәктәп” республика конкурсында лауреат, 2009 елда “Татарстанның иң яхшы мәктәбе” республика конкурсында 3 дәрәҗә диплом иясе булды. Быел коллектив район мәктәпләрен яңа уку елына әзерлек бәйгесендә 1 урынны яулап, кабат премия алды.

Бу казанышларда җитәкченең роле ни дәрәҗәдә икәнлекне 2009 елда Татарстан Республикасының “Иң яхшы мәктәп директоры” исеменә лаек булу да күрсәтеп тора. Ә 2010нчы елда аңа Нурлат районында “Ел ир-аты - хатын-кыз күзлегеннән” җиңүчесе исеме бирелә.

Әйе, алдынгы булу җиңел түгел, кабат үрләр яулау аерым осталык сорый. Кайчандыр яулаган биеклектә калу өчен табигый сәләт, ихтыяр көче, гаять зур тырышлык кирәк. Әлеге югарылыктан бөтен нәрсәгә икенче күз белән карыйсың, яуланмаган өр-яңа биеклекләрне ачасың.

Хәзерге мәгариф системасы баланы белемле итү хакында гына түгел, аңа күнекмәләр бирү, аны эшкә өйрәтү турында да кайгырта. Яңа белем бирү стандартлары куйган таләпләрне уңышлы үтәү коллектив зур көч куеп эшләгәндә генә булачаклыгын яхшы аңлыйбыз.

Йөргән таш шомара, яткан таш мүкләнә, диләр. Мүкләнгән таш хәлендә калмас өчен нишләргә? Ничек барысына да өлгерергә? Бар мәшәкатьләрне бер читкә куеп, замана сулышын эләктерергә тырышабыз.

**Хезмәтебез – мәңге картаймас шатлык чыганагы. Әйе, бу чынлап та шулай, чөнки без - укытучылар. Иң беренче чиратта, бала күңеленә яхшылык, рәхимлелек, сафлык орлыкларын салучылар. Ул кызыксынучан, дөньяны актив танып – белүче, белем нигезләрен яхшы үзләштерүче, мөстәкыйль һәм иҗади, үзенең туган ягын, илен яратучы, гаиләә һәм җәмгыять кыйммәтләрен кабул итүче һәм хөрмәт итүче, үзе эшләгән эшкә гаилә һәм мәктәп алдында җавап бирә белүче, кеше фикерен тыңлый һәм үз фикерен әйтә белүче, сәламәт яшәү рәвеше кагыйдәләрен төгәл үтәүче булырга тиеш.**

**Педагог—оештыручы Ф.В.Билданова** .



## Октябрь аенда туучы кадерле укучыларыбыз:

Гайсин Марсель, Гилязев Әлфис,
Гайсина Вероника, Ситдиков Илнур,
Гафурова Илүзә, Галиуллин Илнар,
Мөхәммәтшин Рәзил!

Сезне барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар , исәнлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!

## Хөрмәтле
## Гөлфия Якуповна !

Сезне чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез.

Сезгә шушы бәйрәмегездә теләкләрнең иң изгесен, иң сафын юллыйбыз. Җаныгыздагы йолдызлар балкышын сүндермичә, күңелегездәге яшәүнең алкышын киметмичә, сәламәтлек дәрьясында коенып яшәвегезне телибез.

Укытучым! Котлы булсын туган көнең,
Матур булып атсын таңнарың.
Рәхәт яшә, игелеге кайтсын
Сез үстергән һәрбер баланың.



Тормыш—бәйрәмсез, бәйрәм котлаусыз булмый.

***

Сүз җан җылысы булса, яхшы теләк күңел кояшы ул.

**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**


**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Билданова Фидалия Вазировна

**Урынбасары:** Әһлиуллин Аяз

**Дизайнер**: Абдрахманова Рәзилә

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Таһирова Гайшә, Гайсина Гөлшат, Садртдинова Рузилә